Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы
Янил авыл җирлеге Советы

КАРАР

«03» апрель 2026 ел №8

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында Нигезләмәгә үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 44 номерлы карары (2015 елның 15 июнендәге 28 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 16 номерлы , 2023 елның 21 сентябрендәге 24 номерлы үзгәрешләр белән);

«Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында белешмәләр бирү турында һәм Янил авыл җирлеге Советының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге Советының 2021 елның 27 июлендәге 17 номерлы карары;

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Янил авыл җирлегенең җирле үзидарә органы муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтта урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырырга бирү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Янил авыл җирлеге Советының 2022 елның 28 апрелендәге 10 номерлы карары.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы: И.Х. Корбанов